КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 26 май г.Казань № б-1006

Татарстан Республикасының нефть-газ химиясе комплексы предприятиеләре арасында хезмәттәшлекне киңәйтү, сәнәгать кооперациясен арттыру һәм нефть сәнәгатенең чимал базасын үстерү максатларында:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының, «Татнефтехиминвест-холдинг» ачык акционерлык җәмгыятенең, В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең, «ТАИФ» акционерлык җәмгыятенең, «Нефтеконсорциум МНК» акционерлык җәмгыятенең, «Газпром межрегионгаз Казань» акционерлык җәмгыятенең, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең, югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең, югары белем бирүче «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең, югары белем бирүче «Казан илкүләм тикшеренү технологик университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең, югары белем бирүче «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты-КАИ» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең, Бөтенроссия фәнни-тикшеренү матдә күләмен үлчәү институты – «Д.И.Менделеев исемендәге Бөтенроссия фәнни-тикшеренү метрология институты» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалының, «Мессе Дюссельдорф Москва» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең, «Казан ярминкәсе» ачык акционерлык җәмгыятенең һәм «Казань Экспо» коммерциягә карамаган автоном оешмасының 2021 елның 31 августында – 2 сентябрендә «Казань Экспо» Халыкара күргәзмә үзәге территориясендә Фән һәм технологияләр елына багышланган һәм түбәндәге чараларны үз эченә алган Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2021не үткәрү турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

«Нефть, газ. Нефть химиясе» XXVIII Халыкара махсуслаштырылган күргәзмәсен;

«GEO-КАЗАН: Геология разведкасы. Геодезия. Картография» XI Махсуслаш-

тырылган күргәзмәсен;

«Интерпластика Казан» VII Халыкара махсуслаштырылган күргәзмәсен;

«Европа берлегенең декарбонизация турындагы карары һәм Россиянең ягулык-энергетика комплексын үстерүнең яңа парадигмасы» халыкара фәнни-гамәли конференциясен;

А.И.Щеповских исемендәге «Сәнәгать экологиясе һәм иминлек» XVI Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясен;

«Энергетика системаларын үстерү перспективалары: икътисадны декарбонизацияләү, водород энергетикасы» халыкара фәнни-гамәли конференциясен;

«Геодезия һәм геомәгълүмат системаларының актуаль мәсьәләләре» X Халыкара фәнни-гамәли конференциясен;

«Сыеклыклар һәм газлар чыгымын һәм күләмен үлчәүләрне метрологик тәэмин итүнең актуаль мәсьәләләре. Углеводород чималының (нефть һәм табигый газның) сыйфаты» IX Халыкара метрология конференциясен;

«Полиолефиннар 2021» халыкара конференциясен;

«Газпром» гавами акционерлык җәмгыятенең төбәк сәясәте комиссиясе күчмә утырышын;

«Төзелеш тармагында республика нефть химиясе продукциясен куллануны киңәйтү» темасына түгәрәк өстәл утырышын;

«Юл төзелешендә нефть химиясе продукциясен куллануны киңәйтү» темасына түгәрәк өстәл утырышын;

«Нефть эшкәртү һәм нефть химиясе сәнәгате предприятиеләре үсеше драйверы буларак тотрыклы энергетика» темасына түгәрәк өстәл утырышын;

«Нефть-газ химиясе комплексы предприятиеләрен кадрлар белән һәм инженерлык ягыннан тәэмин итү: инженерлык педагогикасын үстерү мәсьәләләре» темасына түгәрәк өстәл утырышын;

«Газны исәпкә алуның интеллектуаль системаларын эшләү һәм гамәлгә кертү» темасына түгәрәк өстәл утырышын.

2. Түбәндәгеләр составларын (боерыкка теркәләләр) расларга:

Фән һәм технологияләр елына багышланган Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2021нең оештыру комитеты;

«Европа берлегенең декарбонизация турындагы карары һәм Россиянең ягулык-энергетика комплексын үстерүнең яңа парадигмасы» халыкара фәнни-гамәли конференциясенең программа комитеты;

«Энергетика системаларын үстерү перспективалары: икътисадны декарбонизацияләү, водород энергетикасы» халыкара фәнни-гамәли конференциясенең программа комитеты;

«Геодезия һәм геомәгълүмат системаларының актуаль мәсьәләләре» X Халыкара фәнни-гамәли конференциясенең программа комитеты;

«Сыеклыклар һәм газлар чыгымын һәм күләмен үлчәүләрне метрологик тәэмин итүнең актуаль мәсьәләләре. Углеводород чималының (нефть һәм табигый газның) сыйфаты» IX Халыкара метрология конференциясенең программа комитеты.

3. Түбәндәгеләрне җаваплы итеп билгеләүне тәкъдим итәргә:

«Нефть, газ. Нефть химиясе» XXVIII Халыкара махсуслаштырылган күргәзмәсен әзерләү һәм үткәрү өчен – «Казан ярминкәсе» ачык акционерлык җәмгыятен, «Казаь Экспо» коммерциягә карамаган автоном оешмасын;

«GEO-КАЗАН: Геология разведкасы. Геодезия. Картография» XI Махсуслаштырылган күргәзмәсен әзерләү һәм үткәрү өчен – «Казан ярминкәсе» ачык акционерлык җәмгыятен, «Казань Экспо» коммерциягә карамаган автоном оешмасын;

«Интерпластика Казан» VII Халыкара махсуслаштырылган күргәзмәсен әзерләү һәм үткәрү өчен – «Мессе Дюссельдорф Москва» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятен, «Казань Экспо» коммерциягә карамаган автоном оешмасын;

«Европа берлегенең декарбонизация турындагы карары һәм Россиянең ягулык-энергетика комплексын үстерүнең яңа парадигмасы» халыкара фәнни-гамәли конференциясен әзерләү һәм үткәрү өчен – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесен, В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятен (Татарстан геология разведкасы идарәсе);

А.И.Щеповских исемендәге «Сәнәгать экологиясе һәм иминлек» XVI Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясен әзерләү һәм үткәрү өчен – Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгын;

«Энергетика системаларын үстерү перспективалары: икътисадны декарбонизацияләү, водород энергетикасы» халыкара фәнни-гамәли конференциясен әзерләү һәм үткәрү өчен – «Татнефтехиминвест-холдинг» ачык акционерлык җәмгыятен;

«Геодезия һәм геомәгълүмат системаларының актуаль мәсьәләләре» X Халыкара фәнни-гамәли конференциясен әзерләү һәм үткәрү өчен – Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгын, югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесен, «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесен, «Татарстан Республикасының Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесен, «Татарстан Республикасының Киңлек мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесен;

«Сыеклыклар һәм газлар чыгымын һәм күләмен үлчәүләрне метрологик тәэмин итүнең актуаль мәсьәләләре. Углеводород чималының (нефть һәм табигый газның) сыйфаты» IX Халыкара метрология конференциясен әзерләү һәм үткәрү өчен – Бөтенроссия фәнни-тикшеренү матдә күләмен үлчәү институты – «Д.И.Менделеев исемендәге Бөтенроссия фәнни-тикшеренү метрология институты» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалын;

«Полиолефиннар 2021» халыкара конференциясен әзерләү һәм үткәрү өчен – CREON Conferences, «Казань Экспо» коммерциягә карамаган автоном оешмасын;

«Газпром» гавами акционерлык җәмгыятенең төбәк сәясәте комиссиясе күчмә утырышын әзерләү һәм үткәрү өчен – Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгын, «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятен;

«Газны исәпкә алуның интеллектуаль системаларын эшләү һәм гамәлгә кертү» темасына түгәрәк өстәл утырышын әзерләү һәм үткәрү өчен – «Газпром межрегионгаз Казань» акционерлык җәмгыятен;

«Төзелеш тармагында республика нефть химиясе продукциясен куллануны киңәйтү» темасына түгәрәк өстәл утырышын әзерләү һәм үткәрү өчен – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгын, югары белем бирүче «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесен;

«Юл төзелешендә нефть химиясе продукциясен куллануны киңәйтү» темасына түгәрәк өстәл утырышын әзерләү һәм үткәрү өчен – Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгын, югары белем бирүче «Казан илкүләм тикшеренү технологик университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесен;

«Нефть эшкәртү һәм нефть химиясе сәнәгате предприятиеләре үсеше драйверы буларак тотрыклы энергетика» темасына түгәрәк өстәл утырышын әзерләү һәм үткәрү өчен – югары белем бирүче «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесен;

«Нефть-газ химиясе комплексы предприятиеләрен кадрлар белән һәм инженерлык ягыннан тәэмин итү: инженерлык педагогикасын үстерү мәсьәләләре» темасына түгәрәк өстәл утырышын әзерләү һәм үткәрү өчен – югары белем бирүче «Казан илкүләм тикшеренү технологик университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесен, югары белем бирүче «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты-КАИ» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесен.

4. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, «Татнефтехиминвест-холдинг» ачык акционерлык җәмгыяте, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе, «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе, «Татарстан Республикасының Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Татарстан Республикасының Киңлек мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе, югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе, Бөтенроссия фәнни-тикшеренү матдә күләмен үлчәү институты – «Д.И.Менделеев исемендәге Бөтенроссия фәнни-тикшеренү метрология институты» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы һәм «Казан ярминкәсе» ачык акционерлык җәмгыяте белән берлектә 2021 елның 20 июненә кадәр:

Фән һәм технологияләр елына багышланган Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2021нең программа чараларын;

әлеге чараларны оештыруга һәм үткәрүгә чыгымнар сметасын эшләргә һәм Фән һәм технологияләр елына багышланган Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2021нең оештыру комитетына раслауга кертергә.

5. В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең, «ТАИФ» акционерлык җәмгыятенең, «Нефтеконсорциум МНК» акционерлык

җәмгыятенең «Европа берлегенең декарбонизация турындагы карары һәм Россиянең ягулык-энергетика комплексын үстерүнең яңа парадигмасы» халыкара фәнни-гамәли конференциясен, А.И.Щеповских исемендәге «Сәнәгать экологиясе һәм иминлек» XVI Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясен, «Геодезия һәм геомәгълүмат системаларының актуаль мәсьәләләре» X Халыкара фәнни-гамәли конференциясен, «Сыеклыклар һәм газлар чыгымын һәм күләмен үлчәүләрне метрологик тәэмин итүнең актуаль мәсьәләләре. Углеводород чималының (нефть һәм табигый газның) сыйфаты» IX Халыкара метрология конференциясен, «Газны исәпкә алуның интеллектуаль системаларын эшләү һәм гамәлгә кертү» темасына түгәрәк өстәл утырышын, «Төзелеш тармагында республика нефть химиясе продукциясен куллануны киңәйтү» темасына түгәрәк өстәл утырышын, «Юл төзелешендә нефть химиясе продукциясен куллануны киңәйтү» темасына түгәрәк өстәл утырышын әзерләүне һәм үткәрүне финанслау турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

6. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына Фән һәм технологияләр елына багышланган Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2021не әзерләүдә һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтергә, шулай ук Татарстан Республикасының нефть-газ химиясе комплексы предприятиеләренә һәм оешмаларына – ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) белән берлектә, Фән һәм технологияләр елына багышланган Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2021не үткәрү урыннарында хокук тәртибен һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүдә чараларны оештыручыларга ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

8. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына массакүләм мәгълүмат чараларында Фән һәм технологияләр елына багышланган Татарстан нефть-газ химиясе форумын – 2021не үткәрүне мәгълүмати яктыртуны тәэмин итәргә.

9. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, шулай ук бу боерыкның 3 пунктында чараларны әзерләү һәм үткәрү өчен җаваплы буларак күрсәтелгән министрлыкларга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 26 май, б-1006 нчы
боерыгы белән расланды

Фән һәм технологияләр елына багышланган
Татарстан нефть-газ химиясе форумы – 2021нең оештыру комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, оештыру комитеты рәисе |
| Галиев Ренат Марат улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе, оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абдуллаҗанов Эдвард Юныс улы | югары белем бирүче «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Агиев Шамил Рәхим улы | Татарстан Республикасының Сәүдә-сәнәгать палатасы идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Адиев Эльдар Рәшит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының нефть-газ химиясе комплексы мәсьәләләре буенча ярдәмчесе |
| Астафьев Игорь Владимирович | «Казань Экспо» автоном коммерциягә карамаган оешмасы генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Вәлиев Фәнис Хаммат улы | «Нефтеконсорциум МНК» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Гафуров Илшат Рәфкать улы | югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Гомәров Рөстәм Фәрит улы | Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Казаков Юрий Михайлович | югары белем бирүче «Казан илкүләм тикшеренү технологик университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| Мәганов Наил Өлфәт улы | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер-лык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Миңнуллина Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе |
| Мөхәммәтҗанов Фәргать Госман улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы (җәмәгать тәртибен саклау буенча) урынбасары (килешү буенча) |
| Мөхәммәтшин Ренат Нурислам улы | Идел буе федераль округы буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану департаменты башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Потапов Виктор Васильевич | Әйләнә-тирә мохиткә экологик йогынты ясауның экологик, энергетик һәм икътисадый нәтиҗәлелеген комплекслы бәяләү буенча бәйсез үзәк генераль директоры, Россия Федерациясе Сәүдә-сәнәгать палата-сының табигатьтән файдалану һәм экология комитеты әгъзасы (килешү буенча) |
| Савельчев Алексей Петрович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Сәлахов Мәгъзүм Хәлимулла улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе президенты (килешү буенча) |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сафин Айрат Фоат улы | «Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Семенов Лев Леонидович | «Казан ярминкәсе» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Тайбинский Алексей Семенович | Бөтенроссия фәнни-тикшеренү матдә күләмен үлчәү институты – «Д.И.Менделеев исемендәге Бөтенроссия фәнни-тикшеренү метрология институты» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы директоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Тәхәветдинов Шәфәгать Фәхраз улы | Татарстан Республикасы Президентының нефть сәнәгате мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Томас Штенцель | «Мессе Дюссельдорф Москва» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Улесов Денис Васильевич | «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры (килешү буенча) |
| Фәсхетдинов Марат Гайсә улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының җир асты байлыкларыннан, табигать ресурсларыннан файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы |
| Хәйруллин Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры |
| Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Шадриков Александр Валерьевич | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры |
| Шиһабетдинов Руслан Альберт улы | «ТАИФ» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Эдельгериев Руслан Сайд-Хусайнович | Россия Федерациясе Президенты киңәшчесе, Россия Федерациясе Президентының климат мәсьәләләре буенча махсус вәкиле (килешү буенча) |
| Яруллин Рафинат Самат улы | «Татнефтехиминвест-холдинг» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 26 май, б-1006 нчы
боерыгы белән расланды

«Европа берлегенең декарбонизация турындагы карары һәм
Россиянең ягулык-энергетика комплексын үстерүнең яңа парадигмасы»
халыкара фәнни-гамәли конференциясенең
программа комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Мөслимов Ренат Хәлиулла улы | Татарстан Республикасы Президентының нефть һәм нефть-газ ятмаларын эшкәртү мәсьәләләре буенча консультанты, программа комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Мәганов Наил Өлфәт улы | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры, программа комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |

Программа комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абдуллин Айрат Лесталевич | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе вице-президенты (килешү буенча) |
| Арт Ян Александрович | Дәүләт Думасының Финанс базары комитеты эксперты, Россия сәнәгатьчеләре һәм эшмәкәрләре берлегенең Банклар һәм банк эшчәнлеге комиссиясе әгъзасы, Халыкара менеджмент академиясе академигы, Finversia.ru финанс мәгълүматы порталының баш мөхәррире, Россия банклар ассоциациясе вице-президенты, Мәскәү шәһәре (килешү буенча) |
| Гыйләҗева Татьяна Владимировна | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенә караган Татарстан геология разведкасы идарәсе башлыгының фәнни-тикшеренү һәм тематик эшләр буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Замрий Анатолий Владимирович | Россия нефть-газ сәнәгатьчеләре берлегенең Тармакара эксперт-аналитика үзәге башкарма директоры, Мәскәү шәһәре (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Ибәтуллин Равил Рөстәм улы | TAL Oil Ltd компаниясе директоры, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең хакыйкый әгъзасы (килешү буенча) |
| Крюков Валерий Анатольевич | Россия фәннәр академиясе академигы, «Россия фәннәр академиясенең Себер бүлегенә караган Икътисад һәм сәнәгать җитештерүен оештыру институты» федераль дәүләт бюджет фән учреждениесе директоры, Ресурс икътисады үзәгенең баш фәнни хезмәткәре, «ЭКО» бөтенроссия икътисадый журналы баш мөхәррире, Новосибирск шәһәре (килешү буенча) |
| Нургалиев Данис Карлович | югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең фәнни эшчәнлек буенча проректоры (килешү буенча) |
| Плотникова Ирина Николаевна | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең «Гамәли тикшеренүләр институты» аерымланган структур бүлекчәсенә караган Табигый-фәнни тикшеренүләр үзәгенең төп фәнни хезмәткәре (килешү буенча) |
| Саакян Максим Игоревич | вице-президент, DeGolyer&MacNaughto филиалы директоры урынбасары, Мәскәү шәһәре (килешү буенча) |
| Тәхәветдинов Шәфәгать Фәхраз улы | Татарстан Республикасы Президентының нефть сәнәгате мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Фәррахов Евгений Гата улы | «Россия геологик җәмгыяте» иҗтимагый оешмасының беренче вице-президенты, Мәскәү шәһәре (килешү буенча) |
| Хисамов Рәис Салих улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең хакыйкый әгъзасы (килешү буенча) |
| Хоменко Вадим Васильевич | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе вице-президенты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Христофорова Дарья Анатольевна | «Георесурсы» журналы мөхәррире (килешү буенча) |
| Шаһидуллин Рифгать Роаль улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары институты директоры, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең мөхбир әгъзасы (килешү буенча) |
| Геннадий Шмаль Иосифович | Россия нефть-газ сәнәгатьчеләре берлеге президенты, Мәскәү шәһәре (килешү буенча) |
| Шпуров Игорь Викторович | «Файдалы казылмалар запаслары буенча дәүләт комиссиясе» федераль бюджет учреждениесе генераль директоры (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 26 май, б-1006 нчы
боерыгы белән расланды

«Энергетика системаларын үстерү перспективалары:
икътисадны декарбонизацияләү, водород энергетикасы»
халыкара фәнни-гамәли конференциясенең
программа комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Яруллин Рафинат Самат улы | «Татнефтехиминвест-холдинг» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры, программа комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Салихов Илфат Зилбир улы | «Татнефтехиминвестхолдинг» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары, программа комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |

Программа комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Адиев Эльдар Рәшит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының нефть-газ химиясе комплексы мәсьәләләре буенча ярдәмчесе |
| Мәганов Наил Өлфәт улы | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Сәлахов Мәгъзүм Хәлимулла улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе президенты (килешү буенча) |
| Сафин Айрат Фоат улы | «Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Харлампиди Харлампий Эвклидович | югары белем бирүче «Казан илкүләм тикшеренү технологик университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең гомуми химия технологиясе кафедрасы мөдире (килешү буенча) |
| Шәмсетдинов Эмиль Васил улы | югары белем бирүче «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең тышкы элемтәләрне үстерү департаменты директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Шиһабетдинов Руслан Альберт улы | «ТАИФ» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча). |

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 26 май, б-1006 нчы
боерыгы белән расланды

«Геодезия һәм геомәгълүмат системаларының актуаль мәсьәләләре»
X Халыкара фәнни-гамәли конференциясенең
программа комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Хәйруллин Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры, программа комитеты рәисе |
| Гыйсмәтов Радик Расыйх улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары, программа комитеты рәисе урынбасары |

Программа комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Аввакумов Олег Васильевич | «Идел буенең кадастр инженерлары ассоциациясе» үз-үзен җайга салучы оешмасы президенты – идарә рәисе (килешү буенча) |
| Борисов Александр Сергеевич | «Югары технологияләр өлкәсендәге «ИТ-парк» технопаркы» дәүләт автоном учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Гыйлаев Дамир Мөнзил улы | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсенә караган Топография-геодезия һәм маркшейдерлык эшләре идарәсе башлыгы урынбасары – топография-геодезия һәм маркшейдерлык эшләре бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Заһретдинов Ренат Вәгыйз улы | югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең астрономия һәм космос геодезиясе кафедрасы хезмәткәре (килешү буенча) |
| Исаева Елена Юрьевна | «Татарстан Республикасының Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесенең төзелеш һәм табигатьтән рациональ файдалану өлкәсендә цифрлы нигездә үстерү бүлеге проектының төп җитәкчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Костин Артем Петрович | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Мәүлетдинова Гөлнара Сафиулла кызы | «Идел буе федераль округы буенча Территориаль геологик мәгълүмат фонды» федераль бюджет учреждениесенең Татарстан филиалы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Нургалиев Данис Карлович | югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең фәнни эшчәнлек буенча проректоры (килешү буенча) |
| Огородников Алексей Игоревич | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәгълүмат технологияләре, элемтә һәм мәгълүматны саклау идарәсе башлыгы |
| Садыйков Айрат Халит улы | «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Төбәк автоматлаштырылган мәгълүмат-идарә итү системасы дирекциясе» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |
| Фәсхетдинов Марат Гайсә улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының җир асты байлыкларыннан, табигать ресурсларыннан файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы |
| Шаһидуллин Фәрит Фуат улы | «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры урынбасары (килешү буенча). |

________________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 26 май, б-1006 нчы
боерыгы белән расланды

«Сыеклыклар һәм газлар чыгымын һәм күләмен үлчәүләрне метрологик тәэмин итүнең актуаль мәсьәләләре. Углеводород чималының (нефть һәм табигый газның) сыйфаты» IX Халыкара метрология конференциясенең программа комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Тайбинский Алексей Семенович | Бөтенроссия фәнни-тикшеренү матдә күләмен үлчәү институты – «Д.И.Менделеев исемендәге Бөтенроссия фәнни-тикшеренү метрология институты» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы, программа комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Кузин Александр Юрьевич | «Бөтенроссия фәнни-тикшеренү метрология хезмәте» федераль дәүләт унитар предприятиесе директоры, программа комитеты рәистәше (килешү буенча) |
| Пронин Антон Николаевич | «Д.И.Менделеев исемендәге Бөтенроссия фәнни-тикшеренү метрология институты» федераль дәүләт унитар предприятиесе директоры вазыйфаларын башкаручы, программа комитеты рәистәше (килешү буенча) |

Программа комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Вәгыйзов Рөстәм Шаһит улы | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте баш метрологы (килешү буенча) |
| Ненашкина Светлана Валентиновна | Бөтенроссия фәнни-тикшеренү матдә күләмен үлчәү институты – «Д.И.Менделеев исемендәге Бөтенроссия фәнни-тикшеренү метрология институты» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы директоры урынбасары – баш бухгалтеры (килешү буенча) |
| Рәхимҗанова Лилия Рафаэль кызы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының нефть чыгару һәм нефть эшкәртү бүлеге башлыгы. |